**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15.11.2023 ПР-247 № _____

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 14 ноябрендәге ПР-249 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 01 маендагы 126-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 25 июлендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 14 ноябрендәге ПР-249 номерлы карарына (үзг.белән 05.12.2017 ел, ПР-221, 20.02.2018 ел, ПР-28, 07.12.2021 ел, ПР-241) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру түбәндәге юллар белән тәэмин ителә:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы яисә башка дәүләт яисә муниципаль заказчы тарафыннан дәүләт яисә муниципаль контрактны федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә төзү;

2) концессия килешүләре турында Россия Федерациясе законнары, дәүләти-хосусый партнерлык турында Россия Федерациясе законнары, концессия килешүенең муниципаль-хосусый партнерлыгы турында килешү, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү, шәһәр җир өсте электр транспортының транспорт чараларыннан (трамвайлардан, троллейбуслардан) файдалануны күздә тота торган муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү, халыкның даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен һәм аларны технологик яктан тәэмин итә торган объектларны эксплуатацияләү өчен батареядән (электробуслардан) хәрәкәткә китерелә торган электр энергиясе белән тәэмин ителә торган автобуслардан файдалануны күздә тоткан муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү төзү, әгәр дә ул даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру яисә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең комплексы планы белән каралган булса.»;

- 4.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. Дәүләт яисә муниципаль заказчы, концедент, гавами партнер дәүләт яисә муниципаль контрактның яисә дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүнең гамәлдә булу срогына, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты концессион килешүе яисә дәүләт-хосусый партнерлык турында килешү яисә муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү һәм әлеге Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлешенең 13 пунктында күрсәтелгән белешмәләр даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрына кертелгән затка бирелә.»;

- 12.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.4. Юридик затка, шәхси эшкуарга яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның берсенә бирелгән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты картасы аның гамәлдә булу вакытын озайткан очракта, яисә транспорт чарасы характеристикасы билгеләнгән тәртиптә үзгәргән, үзгәртеп кору рәвешендә юридик затны үзгәртеп төзегән, аның атамасы, тору урыны, адресы үзгәргән, шулай ук яшәү урыны, һәм (яисә) фамилиясе, һәм (яисә) исеме, һәм (яисә) шәхси эшкуарның атасының исеме үзгәргән очракта, мондый шартнамәдә катнашучыларның берсе үлеменә бәйле гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар составы үзгәргән очракта.»;

- 13.6 пунктта «муниципаль контракт» сүзләреннән соң «яки концессион килешү яисә дәүләт-хосусый партнерлык турындагы килешү яисә муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешү нигезендә» сүзләрен, «әлеге контрактның» сүзләрен әлеге контракт яки концессион килешү, дәүләти-хосусый партнерлык яисә муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешү» сүзләренә алмаштырырга.

- 15 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 621DCE305601C88D15496913AD135909
Владелец: Ильясов Рустем Алмазович
Действителен с 10.04.2023 до 03.07.2024

Р.А. Ильясов